Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

ТЫЛСЫМ+

№6 (74)

Март, 2026 нчы ел

Бу санда

Гимназия сулышы 2

Гимназиялеләр Россия беренчелегендә 2

Театр яктылыкка, нурга илтә 2

8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне 3

14 нче март бөек галим яки Пи көне 4

ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

«Ел укытучысы - 2026» бәйгесе

23 нче март көнне Казанның «Әкият» мәдәни үзәгендә «Ел укытучысы - 2026» һөнәри бәйгесенә йомгак ясалды. Бөтенрәсәй һөнәри бәйгесенең йомгаклау өлешендә гимназиянең биология укытучысы Ләйсән Бариева да катнашты. Бу катлаулы этапта Рәсәйнең 11 төбәгеннән, республиканың 15 районыннан барлыгы 32 укытучы көч сынашты. 4 көн дәвамында укытучылар Казан шәһәренең «Адымнар» - белем һәм татулыкка юл» күптелле мәктәбе укучылары белән сыйныф сәгатьләре, дәресләр үткәрделәр, мастер-классларын һәм методик остаханәләрен тәкъдим иттеләр. Бәйгедә Ләйсән Фәхәметдиновна «Методик культура эталоны» номинациясендә җиңү яулады, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының дипломына һәм бүләгенә ия булды.

Зур тәҗрибәгә ия булган, белемле, уңган, талантлы укытучыбызны һөнәри бәйгедәге җиңүе белән тәбрик итәбез. Киләчәктә дә яраткан хезмәтендә һәм шәхси тормышында уңышлар телибез!

«Хезмәткә һәм оборонага әзер бул» (ГТО)

Гимназиянең бертөркем укытучылары Мөслим районы командасы составында, Татарстан Республикасы авыл җирлекләре, хезмәт коллективлары арасында хәрби дан һәм хезмәт батырлыгы елына багышланган "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы фестивальленең зона этабында катнаштылар.

Безнең егет-кызларыбыз I урын яулап, бик яхшы нәтиҗә күрсәттеләр. Команданы искиткеч нәтиҗәләре белән котлыйбыз!

«Аҗаган 2.0» хәрби-патриотик уены

Мөслим гимназиясе базасында «Аҗаган 2.0.» хәрби-спорт уеннарының муниципаль этабы узды. Уенда өч яшь категориясендә мәгариф учреждениеләренең Яшь армия отрядлары катнашты. Укучылар визитка, стройда йөрү осталыкларын, тарих буенча белемнәрен, беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча белемнәрен, командада эшли белү күнекмәләрен бик яхшы күрсәттеләр.

Ярыш нәтиҗәләре буенча кече яшь категориясендә беренче урынга – 3 нче б сыйныфы укучыларының «Патриоты» командасы, урта яшь категориясендә икенче урынга - 6 нчы б сыйныфы укучыларының «Воины гимназии» командасы лаек булды.

ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

Фәнни-гамәли конференция

30 нчы мартта Яр Чаллы шәһәрендә «Батырлыкка мәдхия» Республика фәнни-гамәли конференциясе узды. Чара патриотик тәрбия һәм тарихи хәтерне саклау темасына үз эшләрен тәкъдим иткән талантлы укучыларны берләштерде.

Анда гимназия укучылары да катнашты. 6 нчы сыйныф укучысы Хафизов Әмир II нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. 5 нче а сыйныфы укучысы Газетдинова Камилла III дәрәҗә диплом алды.

Фәнни җитәкчеләре: тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Динара Гайсарова.

«Пушкин укулары»ннан җиңү белән кайттылар

18 нче мартта Яр Чаллы шәһәренең А.С.Пушкин исемендәге 78 нче номерлы лицей базасында "Пушкин укулары" Бөтенроссия ачык иҗади конкурсы узды.

Анда гимназиянең 9 нчы б сыйныфы укучылары Авзалова Сәйдә белән Мадьярова Мәрьям катнашты. Алар «Сәхнә осталыгы» секциясендә чыгыш ясадылар. Кызлар икесе дә I дәрәҗә дипломга лаек булды.

Укучыларның җитәкчесе - рус теле һәм әдәбияты укытучысы Чулпан Хәйруллина.

Илзирә - булдыра!

КФУның Алабуга институтында мәктәп укучыларының «Биология фәннәре: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» исемле төбәк фәнни-гамәли конференциясе узды.

Гимназиянең 10 нчы б сыйныфы укучысы Зиннурова Илзирә I дәрәҗә дипломга лаек булды.

Илзирә, 8-11 нче сыйныф укучылары арасында үткәрелгән, В.И. Вернандский исемендәге Бөтенроссия “Эзләнүчеләр” конкурсының регион турында катнашып III дәрәҗә диплом белән дә бүләкләнде.

Фәнни җитәкчесе – биология укытучысы Ләйсән Бариева.

ГИМНАЗИЯЛЕЛӘР РОССИЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕНДӘ

9–14 март көннәрендә Орёл шәһәрендә армрестлинг буенча Россия беренчелеге узды.

Ярышларда Россиянең 60 төбәгеннән 718 спортчы катнашты.

Алар арасында гимназия укучылары да булу зур сөенеч.

Киеренке көрәш нәтиҗәсендә 11 нче сыйныф укучысы Айзат Әхмәдуллин – ике бронза, 7 нче б сыйныфы укучысы Ислам Бариев – көмеш һәм бронза медальләргә лаек булды.

Укучыларыбызның тренеры - Ларис Бариев.

ТЕАТР - ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ

“Театр – безнең киләчәк көннәребез өчен файдалы вә өметле бер нәрсә”

Г. Тукай

Театр - ул һәрвакыт табышмак, көтелмәгән хәлләр, могҗизалар… Сәхнәдә кечкенә генә булса да роль уйнарга теләмәгән кеше юктыр. Уйлап карасак, тормышта да без, билгесез режиссер язган пьесада, үзебезнең рольләрне башкарабыз бит.

Гимназиядә дә һәр сыйныф театр күрсәтергә алынды. Укучылар сәхнәдә чыгыш ясауны үзләренең көчләрен сынау итеп карыйлар. 10а, 10б, 6б, 7в сыйныфы укучылары бик матур итеп уйнарга да өлгерделәр.

СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ – ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Һәр кешенең әнисе үзенә якын

Әни... бу өч хәрефле гади генә сүздә әйтеп бермәслек тирән мәгънә ята.

Укучылар белән Әмирхан Еникинең “Матурлык” хикәясен укыгач матурлык турында сөйләштек.

“Һәр кешенең әнисе үзенә якын” дигән сорауга укучыларның җаваплары түбәндәгечә яңгырады:

Сәләхов Ранэль: һәр кеше үз әнисен сакларга, яратырга тиеш.

Әхмадуллин Ранис: әни - баласы нинди булуына карамастан, аны яратучы бердәнбер кеше.

Вәлиев Рушат: мин тормышымны әнидән башка күз алдыма да китерә алмыйм.

Мөхәммәтханов Ринал: әниебезнең нурлы йөзе минем өчен зур бәхет.

Тазова Ильвина: әни – дөньяда иң кадерле һәм иң якын кеше.

Латыйпова Иркә: әнием мин мәктәптән кайтуга тәмле ризыклар пешереп куя, без икебез серләшеп чәй эчәбез. Шушы мизгел күңелемә рәхәтлек бирә, мин гел шулай дәвам итүен телим.

Сәетгалиев Данияр: минем әнием бик ягымлы. Аның йомшак тавышы, ягымлы карашы моңсу булганда күңелемне күтәрә. Әнием һәрвакыт мине аңларга тырыша, җылы сүзләре белән күңелемне иркәли.

Тазова Ивилена: бу дөньяда һәр кешенең дә әнисе булсын, әниләрне кадерләп, хөрмәт итеп яшәсәк иде.

Гыйздуллин Рүзәл: мин әниемне бик яратам! Нинди генә булсак та, без - әниләр өчен аның газиз баласы булып калабыз.

Минеева Рүзилә: әни безгә тормыш бүләк иткән, беренче адымнарны ясарга булышкан. Әниләребезне яратыйк, хөрмәт итик!

Сабитов Сәмир: кайда гына булса да бала әнисенең җылысын тоеп яши.

Нурмөхәммәтов Адель: әниләрдән үрнәк алабыз, алар тормышыбызның кояшлары.

Бариева Ралина: әниемне уңышларым белән сөендерергә, аңа авыр булганда янәшәсендә булырга телим. Минем өчен әнидән дә кадерлерәк кеше юк!

Биккинина Камилә: һәркем өчен әни - гади кеше генә түгел, җылылык бөркелүче бербөтен дөнья.

Шәймурзин Алмаз: әниемә рәхмәтлемен, ул минем иң якын кешем.

Шәрифуллин Рүзәл: мин әниемне бик яратам, күңелемдә һәрвакыт әниемә карата җылы хисләр йөртәм.

Солтанова Гөлшат,
Мөслим гимназиясенең педагог-китапханәчесе,
туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы

***

Хатын-кыз - ул серле диңгез төбе,
Хатын-кыз - ул калын бер китап.
Хатын-кыз - ул иксез-чиксез болын,
Җавап табып булмас табышмак.

Телисеңме, ышанычлы дустың
була,
Телисеңме, синең сердәшчең.
Авыр чакта ярдәм кулы сузып,
Була ала синең киңәшчең.

Хатын-кызга бер дә шикләнмичә,
Тапшырырга була һәр эшне.
Тауларны да күчерергә мөмкин,
Хатын-кыз ул менә шундый кеше.

***

Кызык үтә бүген бәйрәм көне,
Матур сүзләр, изге теләкләр...
Чәчәк бәйләмнәре кочак-кочак,
Тузсен генә инде йөрәклар.

Елмаюлар китми, йөзләр якты,
Ашлар тәмле, тыныч күңелләр.
Гел шушылай булсын иде дөнья,
Көнләшепләр куям үземнән.

Матур сүзне әйтер кешең булсын,
Якын дустың булсын яныңда.
Куаныплар уянырга язсын,
Ходай биргән һәрбер таңымда.

Бик бәхетле булып килә минем,
Яшисе дә әле яшисе....
Аяз көнне кукне күкрәтәсе,
Яшен булып килә яшьнисе....

Миләүшә Хәсәнова,
башлангыч сыйныфлар укытучысы

“ЯГЕЗ ӘЛЕ, КЫЗЛАР!” БӘЙГЕСЕ

8 март – халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан, гимназия спортзалында "Ягез әле, кызлар!" бәйгесе үтте.

Бәйгедә 9 нчы, 10 нчы сыйныф укучылары белән берәүттән укытучылар да көч сынашты.

Спорт эстафетасы белән аралаштырып, кызларның хуҗабикә буларак осталыклары да тикшерелде. Гүзәл затларыбыз бер дә сынатмады. Командалар катнаш булгач, егетләр һәнәре дә сынаулар рәтенә керде - автомат сүтеп-җыю командалар өчен сюрприз булды.

9 нчы сыйныф укучылары - беренчелекне, укытучылар командасы - икенче урынны, 10 нчы сыйныфлар - өченче урынны бүлештеләр.

Бу матур чара бик озак хәтерләребездә сакланыр!

14 НЧЕ МАРТ БӨЕК ГАЛИМ ЯКИ ПИ КӨНЕ



Математика һәм фән дөньясында бу кызыклы көн. Нәкъ бу көнне бөтен дөнья **π (пи)** көнен билгеләп үтә. Бу көнне бөек галим Альберт Эйнштейн туган.

Борынгы галимнәр дә бу сан белән меңләгән еллар элек үк кызыксынганнар. Мәсәлән, борынгы грек математигы Архимед ике меңеллар элек, махсус ысул кулланып, **π** санын 3,14 кә якын дип исәпләп чыгарган. Ә бит ул чакта компьютерлар да, калькуляторлар да булмаган!

Умарта корты баш вата!

Корт анасы умата кортына бал җыярга кушкан һәм мондый шартлар үтәргә кирәклеген әйткән.

1 аягы – 1 чиләк бал, 2 нчесенә - 2, 3 нсенә - 3, 4 нчесенә - 4, 5 есенә - 5, 6 сына – 6 чиләк бал салырга кирәк һәм туры сызыкта яткан оялардагы балның күләме 12 чиләк булырга тиеш.

Умарта корты моны ничек эшли алган?



Уйлап кара!



1. Дүрт “9” санын 100 булырлык итеп ничек куеп була?
2. Чираттагы сан нинди? 7645, 5764, 4576, ...
3. Бүлмәдә 5 чеби, 2 куян, 5 көчек, 2 песи һәм 2 тавык бар, Алар янына хуҗа үз эте белән керде. Бүлмәдә ничә аяк булды.
4. 3 уңай сан бирелгән. Бу саннарны куша да, тапкырлый да аласыз. Әмма җавап ике очракта да бертөрле булачак. Бу нинди саннар?

Әзерләде: Насырова Мәрьям

ӘЛИФБА БӘЙРӘМЕ

Гимназиядә “Әлифба бәйрәме” үткәрелде. Беренче сыйныф укучылары белем дөньясындагы беренче җиңүләрен бәйрәм иттеләр. Бәйрәмгә балаларның әти-әниләре дә кунак булып килде. Укучылар бәйрәмдә җырладылар, биеделәр, шигырьләр сөйләделәр. Бәйрәм бик күңелле үтте. Балалар, азбуканы, әлифбаны өйрәтүдә зур тырышлык куйган укытучыларына, әти-әниләренә рәхмәтләрен җиткерделәр. Алар алдында тырыш булырга, ялкауланмаска, алдынгылар рәтендә булырга, "2" ле алмаска, "4"-"5" кә генә укырга сүз бирделәр. Ә без беренче сыйныф укучыларын бәйрәм белән котлыйбыз, киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз!

ЯЗ БӘЙРӘМЕ – НӘҮРҮЗ!

4 нче а сыйныфы укучылары һәм сыйныф җитәкчеләре Э.С. Ермолаева һәм Үзәк балалар китапханәсе хезмәткәрләре бергә төрки халыкларның милли фольклор бәйрәмнәренең берсе - «Нәүрүз - яз бәйрәме» үткәрделәр. Бәйрәм гимназия территориясендә, саф һавада үтте.

Нәүрүз бәйрәме - борынгы бәйрәм. Аны 21 мартта - язгы көн-төн тигезлегендә, Азиянең күп илләрендә һәм Россиянең кайбер төбәкләрендә яшәүчеләр билгеләп үтәләр.

Әлеге бәйрәм чарасы Мәслим гимназиясенең башлангыч сыйныф укучылары өчен оештырылды. Бәйрәм төрле милли уеннар, җырлар, такмаклар белән үрелеп барды. Балалар бәйрәмнең барлыкка килү тарихы, халык традицияләре һәм гореф-гадәтләре, бу бәйрәмгә әзерләнә торган милли ризыклар белән таныштылар.

Кунакка Нәүрүз-яз, Кыш бабай, Кояш, кара карга, язгы ләйсән яңгыры килде. Барлык милли бәйрәмнәрдәге кебек үк, халык уеннары үткәрелде: капчык киеп, йомырка кабып йөгерү, «водонослар", аркан тартышу.

ТЫЛСЫМ+
Март, 2026 нчы ел
№6 (74)
Мәслим гимназиясе укучылары газетасы

Баш мөхәррир: Солтанова Г.М.
Техник редактор: Кадыйрова А.Р.

Мөхәррир: Замалова Зәринә
Корректорлар: Хәйруллина Диләрә
Корреспондентлар: Насырова Мәрьям
Фәхрәзиева Алинә
Дизайнер: Мостафина Рәйлә
Компьютерда җыючылар: Вагыйзов Айзат
Сәләмов Наил

2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә

Гамәлгә куючы:
Мәслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
Адрес: Мәслим, Кооператив урамы, 170а
Сайт: https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
Электрон адрес: tilsim2014@yandex.ru
Формат: А4 (А3)
Тираж: 100